**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17 нче йорт. Тел.3-02-22. Факс 3-13-44

**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-02-22. Факс 3-13-44

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2018г № ПР-204

«Актаныш муниципаль районы Актаныш авылы үзәгеннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан, Актаныш муниципаль районының ерак һәм халык саны аз булган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен кайтару өчен, Актаныш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү тәртибе турында» ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 01 декабрендәге ПР-217 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 июлендәге 615 нче номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы районнары үзәкләреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан, Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы составына керүче җирлекләрне җәмәгать туклануы, сәүдә белән тәэмин итүгә шартлар тудыру буенча, Актаныш муниципаль районының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатыннан

**карар бирәм:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 ел, 01 декабрь, ПР-217 нче номерлы карары белән расланган «Актаныш муниципаль районы Актаныш авылы үзәгеннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан, Актаныш муниципаль районының ерак һәм халык саны аз булган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен кайтару өчен, Актаныш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү», түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.1. пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Башка бюджетара трансфертларны алучыларга башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 июль, 615 нче номерлы карары белән раслана «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы районнары үзәкләреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан, Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган куллану кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче карары белән расланган».».

2) Актаныш муниципаль районы Актаныш авылы үзәгеннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан, Актаныш муниципаль районының ерак һәм халык саны аз булган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен кайтару өчен Актаныш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү буенча комиссия составын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 ел, 1 декабрендә чыккан ПР - 217 номерлы «ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 ел, 20 декабрь, ПР- 235 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы «Актаныш муниципаль районы Актаныш авылы үзәгеннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан, Актаныш муниципаль районының ерак һәм халык саны аз булган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен кайтару өчен Актаныш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү тәртибен раслау турында» »карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Сираева